РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2023г. г. Альметьевск № 212

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 343 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 40 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 144 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаның «Район башкарма комитеты җитәкчесе» 3 бүлегендә:

1.1.1. 3.10.1 пунктының еченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 3.10.2 пунктының беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән соң) үз кеченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны районның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»